ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

04.03.2022　　　с. Верхний Услон　　　222

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен
тәэмин итү буенча төп чаралар планын раслау һәм оператив штаб төзү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.02.2022 ел №387-р әмере нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне раслварга:

Югары Ослан муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча төп чаралар планы, 1 нче кушымта нигезендә.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча төп чаралар планын гамәлгә ашыру буенча оператив штаб составы, 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе　　　　　　　　　　И. И. Шакиров

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
______ 2022 ел ________ карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча төп чаралар планы

| № т/б | Чараның атамасы | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Беренче зарурлык товарлары белән тәэмин итү һәм халыкка ярдәм | | | |
| 1.1. | Кулланучылар бәяләренең оператив мониторингы | атна саен | ТР ЮМР Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Югары Ослан муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| 1.2. | Баланс комиссияләрендә куллану товарларына бәяләрнең шактый читкә тайпылу сәбәпләрен карау | кирәк булганда | |
| 1.3. | Сәүдә оешмаларында беренче зарурлык товарлары булуга оператив мониторинг ясау, шул исәптән | көн саен | ТР ЮМР Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Югары Ослан муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| | азык-төлек продуктлары | | ТР ЮМР Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Югары Ослан муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| | балалар товарлары | | ТР ЮМР Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | дарулар, медицина эшләнмәләре, дезинфекция һәм индивидуаль яклау чаралары | | ТР ЮМР Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |
| 1.4. | Авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрү | даими | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| 1.5. | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында хезмәт базарындагы вазгыятькә оператив мониторинг | атна саен | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 1.6. | Мәшгульлеккә актив ярдәм чараларын гамәлгә ашыру | даими | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ |
| 1.7. | Предприятиеләр хезмәткәрләрен эштән азат итү һәм аларны яңа төзеләторган эш урыннарына эшкә урнаштыру мөмкинлекләрен бәяләү | | |
| 1.8. | Азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләрне яңадан укытуны һәм квалификацияләрен арттыруны оештыру | | |
| | 2. Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм | | |
| 2.1. | Бизнестан кире элемтә юлы белән кече һәм урта эшкуарлык өлкәсе торышын мониторинглау | даими | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 2.2. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү буенча тәкъдимнәр әзерләү | кирәк булганда | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 2.3. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чараларын гамәлгә ашыру | даими | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты |
| | 3. Гомуми системага салынган чаралар | | |
| 3.1. | Бюджет чыгымнарын оптимальләштерү турында тәкъдимнәр | кирәк булганда | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | әзерләү | | |

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының __________
2022 ел ________ карарына
2 Кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча төп чаралар планын гамәлгә ашыру буенча
Оператив штаб составы

| | |
|---|---|
| Шакиров Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Оператив штаб җитәкчесе |
| Манапова Наталья Юрьевна | Социаль-икътисадый үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, Оператив штаб җитәкчесе урынбасары |
| Сельская Олеся Александровна | ТР Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы, Оператив штаб секретаре |

Оператив штаб әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Черменский Максим Михайлович | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, элемтә һәм энергетика буенча беренче урынбасары |
| Камалетдинова Гөлия Фидаил кызы | Социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |

| | |
|---|---|
| Колесова Елена Евгеньевна | ТР Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы рәисе |
| Потапова Любовь Петровна | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе |
| Гобәйдуллин Рәшит Галимҗан улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы |
| Габдрахманова Алинә Рим кызы | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ директоры |
| Муфталиев Нусрет Заһидә улы | Филиал директоры - «Татмедиа» АҖ филиалы - «Волжская новь» газетасы редакциясе баш мөхәррире |